**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «НОВОТРОИЦК» АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«12» декабрь 2023 ел № 39/2

**2024 елга, 2025, 2026 еллар планы чорына Новотроицк авыл җирлеге бюджеты турында**

1 статья

1. 2024 елга Новотроицк авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Новотроицк авыл җирлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 23 163,78 мең сум;

2) Новотроицк авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 23 163,78 мең сум.

3) Новотроицк авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 0 сум.

2. 2025, 2026 елларга Новотроицк авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Новотроицк авыл җирлеге бюджет керемнәренең гомуми күләме 2025 елга 24 378,86 мең сум, 2026 елга 25 089,87 мең сум;

2) Новотроицк авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен:

- 2025 елга 24 378,86 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 597,58 мең сум;

- 2026 елга 25 089,87 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 1 231,26 мең сум.

3) 2025 елга Новотроицк авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0 сум һәм 2026 елга 0 сум.

3. Новотроицк авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын расларга:

- 2024 елга әлеге карарга 1 кушымта нигезендә;

- 2025 һәм 2026 еллар планы чорына әлеге карарга 2 кушымта нигезендә.

2 статья

1. 2025 елның 1 гыйнварена Новотроицк авыл җирлеге эчке муниципаль бурычының югары чиген 0 сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 сум күләмендә расларга.

2. 2026 елның 1 гыйнварена Новотроицк авыл җирлеге эчке муниципаль бурычының югары чиген 0 сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 сум күләмендә расларга.

3. 2027 елның 1 гыйнварена Новотроицк авыл җирлеге эчке муниципаль бурычының югары чиген 0 сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 сум күләмендә расларга.

3 статья

1. Новотроицк авыл җирлеге бюджетында 2024 елга фаразланган керемнәр күләмен әлеге карарга 3 кушымта нигезендә исәпкә алырга.

2. Новотроицк авыл җирлеге бюджетында 2025 һәм 2026 еллар планы чорына

фаразланган керемнәр күләмен әлеге карарга 4 кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.13 статьясы нигезендә Новотроицк авыл җирлеге бюджетыннан Тукай муниципаль районы бюджетына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар күләмен расларга:

- төзеклэндерү кысаларында авыл җирлекләре автомобиль юлларын карап тоту (юлларны кышкы чистарту) буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тапшыруга 2024 елга – 2 400,0 мең сум, 2025 елда – 2 400,0 мең сум, 2026 елда 2 400,0 мең сум күләмендә;

- җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ялны оештыру өчен шартлар тудыру буенча чараларны тәэмин итүгә төзелгән килешүләр буенча 2024 елга – 2 359,0 мең сум, 2025 елга – 2 359,0 мең сум, 2026 елга 2 359,0 мең сум күләмендә.

2024-2026 елда бюджетара трансфертларны күчерү ай саен тигез өлешләр белән башкарыла дип билгеләргә.

5 статья

1. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.13 статьясы нигезендә чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен, Новотроицк авыл җирлеге бюджетыннан Тукай муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара трансфертлар күләмен 2024 елга – 11 340,9 мең сум, 2025 елга – 12 146,7 мең сум, 2026 елга 13 094,1 мең сум күләмендә расларга.

6 статья

1. Новотроицк авыл җирлеге чыгымнарының ведомство структурасын расларга:

- 2024 елга елга әлеге карарга 5 кушымта нигезендә;

- 2025, 2026 еллар планы чорына әлеге карарга 6 кушымта нигезендә.

2. Бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне расларга:

- 2024 елга елга әлеге карарга 7 кушымта нигезендә;

- 2025, 2026 еллар планы чорына әлеге карарга 8 кушымта нигезендә.

3. Бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнарының максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программасыз юнәлешләре), бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне расларга:

- 2024 елга елга әлеге карарга 9 кушымта нигезендә;

- 2025, 2026 еллар планы чорына әлеге карарга 10 кушымта нигезендә.

4. Новотроицк авыл җирлеге бюджетының гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2024 елга – 0 сум, 2025 елга – 0 сум, 2026 елга 0 сум күләмендә расларга.

7 Статья

Новотроицк авыл җирлеге бюджетында 2024 елга җирлекләрнең, муниципаль һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алу өчен муниципаль районнар бюджетларына 402,0 мең сум күләмендә субвенцияләр күләмен исәпкә алырга; 2025 елга 475,0 мең сум, 2026 елга 464,6 мең сум күләмендә.

8 статья

2024 елда Новотроицк авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

9 статья

Новотроицк авыл җирлеге бюджеты калдыклары Новотроицк авыл җирлеге исеменнән товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән муниципаль контрактлар өчен түләүгә (әлеге муниципаль контрактларның шартлары нигезендә 2024 елда түләнергә тиеш) файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә 2024 елда, Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

10 статья

Әлеге карарны Новотроицк авылы (Ленин урамы, 16 й.) территориясендә урнашкан махсус стендларда урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

11 статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Тукай муниципаль районы буенча территориаль органнары төзелгән килешүләр нигезендә Новотроицк авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

12 статья

Әлеге карар 2024 елның 1 январеннан үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе Д.М. Габделхаева